ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15 ноябрь 2022 ел** **№ 3**

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенә керүче Алма-Ата торак пунктында 2023 елдаүзара салым кертү һәм ул акчаларны куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 8 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 16 ноябрендә 13.00 сәгатькә ТР, Ютазы муниципаль районы, Алма-Ата торак пункты, Яшел ур., 1а йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында (авыл мәдәният йорты) Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлеге Алма-Ата торак пунктында 2023 елда гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Җыенга чыгарылган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Ютазы авыл җирлегенә керүче Алма-Ата торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче Бөек Ватан сугышы ветераннары, Украинада махсус хәрби операциядә катнашучылардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә сез ризамы һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, ягъни түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме:

-Алма-Ата торак пунктында зират территориясендә коймаларны ремонтлау (төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эш өчен түләү);

-Алма-Ата торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эш өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Ютазы авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын

оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// jutaza.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов